**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«25» февраль 2021 с. Тюлячи № 73

Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 18 июнендәге 367 номерлы «Теләче муниципаль районында үзәкләштерелгән бухгалтерия җитәкчеләре һәм белгечләренең, муниципаль берәмлекләрнең Башкарма комитетлары баш бухгалтерларының һәм бухгалтерларының (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш) хезмәт хакын оештыру һәм түләү шартлары турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 5 августындагы 655 номерлы, 2020 елның 6 августындагы 658 номерлы карарлары нигезендә, Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Район Башкарма комитетының 2019 елның 18 июнендәге 367 номерлы «Теләче муниципаль районында үзәкләштерелгән бухгалтерия җитәкчеләре һәм белгечләренең, муниципаль берәмлекләрнең Башкарма комитетлары баш бухгалтерларының һәм бухгалтерларының (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш) хезмәт хакын оештыру һәм түләү шартлары турында» карар белән расланган Теләче муниципаль районының «Үзәкләштерелгән бухгалтерия» МКУ җитәкчеләре һәм белгечләренең хезмәте өчен түләүне оештыру һәм шартлары турында Нигезләмәнең 3 пунктына үзгәрешләр кертергә һәм яңа редакциядә бәян итәргә:

«3. Теләче муниципаль районы «Үзәкләштерелгән бухгалтерия» МКУ җитәкчеләре һәм белгечләренең хезмәт хаклары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Җитәкчеләр һәм белгечләр вазыйфалары | Вазыйфаи оклад, сум |
|---|---|
| | Муниципаль учреждение булып торучы үзәкләштерелгән бухгалтерия өчен |
| Муниципаль учреждение җитәкчесе | 24411 |

| | |
|---|---|
| Муниципаль учреждение җитәкчесе урынбасары | 22145 |
| Бүлек башлыгы | 18231 |
| Әйдәп баручы бухгалтер | 15759 |
| Бухгалтер | 14420 |

Муниципаль учреждение булып торучы үзәкләштерелгән бухгалтериянең штат расписаниесенә кертү шарты булып, структурада кимендә 5 берәмлек штатлы 3 бүлек булу тора.

Үзәкләштерелгән бухгалтерия бүлекләре штатта 5 берәмлектән дә ким булмаган санда булырга тиеш.».

2. Район Башкарма комитетының 2019 елның 18 июнендәге 367 номерлы «Теләче муниципаль районында үзәкләштерелгән бухгалтерия җитәкчеләре һәм белгечләренең, муниципаль берәмлекләрнең Башкарма комитетлары баш бухгалтерларының һәм бухгалтерларының (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш) хезмәт хакын оештыру һәм түләү шартлары турында» карар белән расланган муниципаль берәмлекләр башкарма комитетларының баш бухгалтерларының һәм бухгалтерларының (Теләче муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләре вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш) хезмәте өчен түләүне оештыру һәм шартлары турында Нигезләмәнең 3 пунктына үзгәрешләр кертергә һәм яңа редакциядә бәян итәргә:

«3. Бухгалтерларның вазыйфаи окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Вазифасы | Муниципаль берәмлекләрнең Башкарма комитетлары | |
|---|---|---|
| | Халык саны 3,5 меңгә кадәр булган | 3,5 меңнән артык кеше |
| Баш бухгалтер | - | 17510 сум |
| Бухгалтер | 14935 сум | 14935 сум |

3. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә һәм 2020 елның 1 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Җитәкче И.Х. Хәмидуллин